**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

**29.12.2015** **№ 1126-п**

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 23.04.2012, № 148-п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының калдыклар барлыкка килү, алардан файдалану, аларны йогышсызландыру һәм урнаштыру турында хисап (статистика хисабыннан тыш) тапшыру хакында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының норматив-хокукый актларын законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:
1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 23.04.2012, № 148-п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының калдыклар барлыкка килү, алардан файдалану, аларны йогышсызландыру һәм урнаштыру турында хисап (статистика хисабыннан тыш) тапшыру хакында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 кисәктә:

1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүче калдыклар барлыкка килү, алардан файдалану, аларны йогышсызландыру һәм урнаштыру турында хисап (статистика хисабыннан тыш) тапшыра.

Хисап чоры бер календарь елыннан тора. Юридик зат яки шәхси эшмәкәр тарафыннан кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына карый торган хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлеге гамәлгә ашырыла башлаган очракта хисапның календарь

елы дәвамында хисап чоры күрсәтелгән юридик зат яки шәхси эшмәкәр дәүләт теркәвенә алынган датадан башлап исәпләнә.

Барлыкка килү, алардан файдалану, аларны йогышсызландыру һәм урнаштыру турында хисап (статистика хисабыннан тыш) ел саен хисап елыннан соң килүче елның 1 мартына кадәр тапшырыла.";

1.3 – 1.3.3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан Министрлыкның территориаль идарәләре аша күрсәтелә.

1.3.1. Министрлык урнашкан урын: Казан ш., Павлюхин ур., 75 йорт.

Министрлыкка дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча документлар һәм мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен почта адресы: 420049, Татарстан Республикасы, Казан ш., Павлюхин ур., 75 йорт.

Министрлыкның һәм Министрлыкның Үзәк территориаль идарәсенең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Министрлыкның белешмә телефоннары: (843) 267-68-81, 264-49-37 (әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормага салу бүлеге).

Җәмәгать транспортында "Павлюхин" тукталышына кадәр килергә кирәк:

автобуслар: №№ 2, 4, 5, 25, 31, 37, 43, 47, 69, 69а, 74, 74а, 77;

троллейбуслар: №№ 6, 8, 12.

Керү шәхесне таныклый торган документ нигезендә башкарыла.

1.3.2. Министрлыкның территориаль идарәләренең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Керү шәхесне таныклый торган документ нигезендә башкарыла.

Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы территориаль идарәләре турында мәгълүмат 1 таблицада.

**1 таблица. Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы территориаль идарәләре турында мәгълүмат**

| Территориаль орган | Адрес | Телефон, электрон почта адресы | Җәмәгать транспортында килү | Хезмәт күрсәтелә торган территорияләр |
|---|---|---|---|---|
| Үзәк территориаль идарә | 420049, Казан ш., Павлюхин ур., 75 йорт. | (843) 267-68-33 I.Sabirov@tatar.ru | Автобуслар: №№ 2, 4, 5, 25, 31, 37, 43, 47, 69, 69а, 74, 74а, 77; Троллейбуслар | Казан ш. Биектау муниципаль районы (алга таба - МР), Лаеш МР, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | : №№ 6, 8, 12 “Павлюхин” тукталышына кадәр | Питрәч МР, Югары Ослан МР, Балык Бистәсе МР, Саба МР, Теләче МР, Яшел Үзән МР |
| Төньяк территориаль идарә | 422000, Арча ш., Интернациональ ная ур., 41 й. | (84366) 3-21-61 sevtu@mail.ru | автобус | Арча ш., Арча МР, Әтнә МР, Балтач МР, Кукмара МР |
| Идел арты территориаль идарәсе | 422430, Буа ш., Р.Люксембург ур., 159/1 йорт | (84374) 3-11-02 3-34-46 zvtu@bk.ru | № 1 автобус белән “Люксембург” тукталышына кадәр | Буа ш., Буа МР, Апас МР, Чүпрәле МР, Кайбыч МР, Кама Тамагы МР, Тәтеш МР |
| Идел-Кама территориаль идарәсе | 422980, Чистай ш., Фрунзе ур., 97а йорт | (84342) 5-35-19 5-03-68 Rafis.Ahmetzyanov@tatar.ru | №№ 1, 21 автобуслар белән “Фрунзе” тукталышына кадәр | Чистай ш., Чистай МР, Аксубай МР, Алексеевск МР, Әлки МР, Спас МР, Яңа Чишмә МР |
| Кама арты территориаль идарәсе | 423552, Түбән Кама районы, Красный Ключ бистәсе, Набережная ур, 7 йорт | (88555) 45-66-56 43-90-70 zakamtu@mail.ru | № 2 трамвай белән “Красный Ключ” тукталышына кадәр | Түбән Кама ш., Түбән Кама МР, Зәй МР, Сарман МР |
| Кама буе территориаль идарәсе | 423838, Чаллы ш., Җиңүгә 40 ел урамы, 64 йорт | (8-8552) 59-36-39 59-50-46 prirodart@mail.ru | №№ 1б, 3, 10а, 25, 35 автобуслары белән “Форт Диалог” тукталышына кадәр | Чаллы ш., Тукай МР, Актаныш МР, Әгерҗе МР, Менделеевск МР, Минзәлә МР, Мамадыш МР, Алабуга МР |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Ык буе территориаль идарәсе | 423330, Азнакай ш., Шоссейная ур., 6 йорт | (8-85572) 2-39-86 (8-85592) 51-5-38 eco.azn@mail. ru | № 5а автобусы белән “Шоссейная” тукталышына кадәр | Азнакай ш., Азнакай МР, Бавлы МР, Мөслим МР, Ютазы МР |
| Көньяк-Көнчыгыш территориаль идарәсе | 423450, Әлмәт ш, Әминов ур., , 9а йорт | (8-8553) 33-03-25 33-03-27 uvgri@tatais.ru | № 5 автобус; № 1 троллейбус белән “Әминов” тукталышына кадәр | Әлмәт ш., Бөгелмә МР, Лениногорск МР, Нурлат МР, Чирмешән МР |

1.3.3. Министрлыкның “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасын составына керә торган рәсми сайт адресы (алга таба – тиешенчә: “Интернет” челтәре һәм Министрлыкның рәсми сайты): http://eco.tatarstan.ru, электрон почта адресы: eco@tatar.ru.»;

1.3.4 пунктында:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) Министрлык биналарында һәм Министрлыкның территориаль идарәләре биналарында урнашкан, дәүләт хезмәте турында мәгълүматны үз эченә алучы мәгълүмат стендлары ярдәмендә;”;

3 һәм 4 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) Министрлыкка һәм/яки Министрлыкның территориаль идарәләренә телдән (шәхсән яки телефон аша) мөрәҗәгать иткәндә;

“4) Министрлыкка һәм/яки Министрлыкның территориаль идарәләренә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.”;

1.3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Мәгълүмат стендларына урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 1.3.2, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала.”;

1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1998 елның 24 июнендәге “Җитештерү һәм куллану калдыклары турында” № 89-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 89-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 1998, № 26, 3009 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2002 елның 10 гыйнварындагы “Әйләнә-тирә мохитне саклау турында” № 7-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 7-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 2002, № 2, 133 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2010 елның 27 июлендәге “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль

закон) (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгының 2001 елның 15 июнендәге “Куркыныч калдыкларны әйләнә-тирә табигый тирәлек өчен куркыныч классына кертү критерийларын раслау турында” № 511 боерыгы (Природно-ресурсные ведомости, 2001, № 45);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгының 2011 елның 30 сентябрендәге “Дәүләт калдыклар кадастрын алып бару тәртибен раслау турында” № 792 боерыгы (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене, 2011, № 50);

2009 елның 15 гыйнварындагы № 5-ТРЗ Татарстан Республикасы Экология кодексы (алга таба – ТР Экология кодексы) (Татарстан Дәүләт Советының җыелма басмасы, 2009, № 1, 5 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы мәсьәләләре” № 325 карары (алга таба – № 325 ТР МК карары) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2005, № 28, 0654 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” 880 номерлы карары (алга таба – Тәртип) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).”;

1.5 пунктын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

**җитештерү һәм куллану калдыклары** (алга таба – калдыклар) – Җитештерү барышында, эшләр башкарганда, хезмәтләр күрсәткәндә яки куллану барышында барлыкка килгән, бетерелә торган, бетерү өчен билгеләнгән яки бетерелергә тиешле матдәләр яки предметлар;

**калдыклар белән эш итү** – калдыкларны җыю, туплау, транспортлаштыру, эшкәртү, йогышсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлек;

**калдыкларны урнаштыру** – калдыкларны саклау һәм күмү;

**калдыкларны саклау** – калдыкларны утильләштерү, йогышсызландыру, күмү максатларында унбер айдан артык вакытка махсуслаштырылган объектларга кую;

**калдыкларны күмү** – алга таба юк ителергә тиешле булмаган калдыкларны зарарлы матдәләр әйләнә-тирә мохиткә эләкмәсен өчен махсус саклагычларда изоляцияләү;

**калдыкларны утильләштерү** – калдыкларны, калдыкларны турыдан-туры билгеләнеше буенча яңадан куллануны (рециклинг) кертеп, товарлар (продукция)

җитештерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өчен куллану, аларны тиешле әзерлектән соң җитештерү циклына кайтару (регенерация), шулай ук аларны кабат куллану өчен файдалы компонентларын алу (рекуперация);

**калдыкларны йогышсызландыру** – калдыкларның кеше сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә булган тискәре йогынтысын киметү максатларында калдыкларның массасын киметү, аларның составын, физик һәм химик үзенчәлекләрен үзгәртү (аларны махсус җайланмаларда яндыруны һәм (яки) йогышсызландыру кертеп);

**калдыклар паспорты** – калдыкларның тиешле төргә һәм куркыныч классына караганлыгын таныклый торган, аларның составы турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ;

**калдыкларның төре** – калдыкларны классификацияләү системасы нигезендә гомуми билгеләргә ия булган калдыклар җыелмасы;

**калдыкларны җыю** – калдыкларны алга таба эшкәртү, утильләштерү, йогышсызландыру, транспортлаштыру, мондый калдыкларны урнаштыру максатларында физик затлардан һәм юридик затлардан калдыкларны кабул итеп алу яки аларның килүе;

**калдыкларны транспортлаштыру** – транспорт чаралары ярдәмендә калдыкларны юридик зат яки шәхси эшмәкәр милегендә булган яки аларга башка хокукларда тапшырылган җир кишәрлегеннән башка урынга күчерү;

**калдыкларны туплау** – аларны алга таба утильләштерү, йогышсызландыру, урнаштыру, транспортлаштыру максатларында калдыкларны әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә законнарның һәм халыкны санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өлкәсендә законнарның таләпләре нигезендә җиһазландырылган урыннарда (мәйданнарда) вакытлыча (алты айдан да күбрәк булмаган чорга) урнаштыру;

**калдыкларны эшкәртү** – сортларга аеру, сүтү, җыюны кертеп, калдыкларны алга таба утильләштерү өчен беренчел әзерләү;

**техник хата** – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелә торган белешмәләрнең төгәлсезлегенә китергән белешмәләр кертелгән документтагы (дәүләт хезмәте нәтиҗәсе) хата (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата);

**дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтү буенча күп функцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны** – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, мөрәҗәгать итүчеләрне консультацияләү тәрәзәсе.

Әлеге регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) мөрәҗәгать итүченең № 210-ФЗ Федераль законның 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәсе аңлашыла. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентка карата 2 кушымтада китерелә.”;

2 кисәктә:

“Стандарт таләбенең аталышы” графасының исемен түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы”;

“Стандарт таләбенең эчтәлеге” графасының аталышын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге”;

“Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт” графасының 2.1 һәм 2.9 пунктларында “№ 325 ТР МК карарының 3.3.7 п.” сүзләрен “ТР МК № 325 карары белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы турында нигезләмәнең 3.3.7 п.” сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктында:

“Стандарт таләбенең эчтәлеге” графасына “(алга таба – Министрлык) Министрлыкның территориаль идарәләре аша” сүзләрен өстәргә;

“Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт” графасында “№ 325 ТР МК карарының 3.3.7 п.” сүзләрен “ТР МК № 325 карары белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы турында нигезләмәнең 3.3.7 п.” сүзләренә алмаштырырга;

“Стандарт таләбенең эчтәлеге” графасындагы 2.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Министрлыкның территориаль идарәсенең шушы Регламентка карата 1 кушымтага нигезләнеп Хисапны кабул итү турында бәяләмә яки шушы Регламентның 3 кушымтасына нигезләнеп, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат”;

2.4 пунктында:

“Стандарт таләбенең аталышы” графасын “, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, әгәр дә туктату мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату срогы”;

“Стандарт таләбенең эчтәлеге” графасында “30 календарь” сүзләрен “22 эш” сүзләренә алмаштырырга;

“Стандарт таләбенең аталышы” графасында 2.5 пунктына “мөрәҗәгать итүче күрсәтергә тиешле” сүзләреннән соң “, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан, шул исәптән электрон рәвештә алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе”;

“Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт” графасында 2.5 һәм 2.8 пунктларында “РФ Табигый ресурслар министрлыгының № 30 боерыгының 12 п.” сүзләрен “РФ Табигый ресурслар министрлыгының № 30 боерыгы белән расланган Калдыклар барлыкка килү, алардан файдалану, аларны йогышсызландыру һәм урнаштыру турында хисап (статистик хисаптан тыш) тапшыру һәм контрольдә тоту тәртибенең 12 п.” сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктында:

“Стандарт таләбенең аталышы” графасын “мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы” сүзләреннән соң “, шулай ук аларны мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан, шул исәптән электрон рәвештә алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; шушы документлар алар идарәлегендә булган дәүләт органы, бирле үзидарә органы яки оешма” сүзләре белән тулыландырырга;

“Стандарт таләбенең эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“1. Хисап тапшыручы хуҗалык итүче субъектның (I - IV куркыныч классындагы калдыкларны җыю, транспортлаштыру, эшкәртү, утильләштерү, йогышсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлек башкаручы шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар өчен) I - IV куркыныч классындагы калдыкларны җыю, транспортлаштыру, эшкәртү, утильләштерү, йогышсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлек башкару турында лицензиянең күчермәсе (Татарстан Республикасы буенча Росприроднадзор идарәсе).

2. Хисап тапшыручы хуҗалык итүче субъект хисап чорында I - IV куркыныч классындагы калдыкларны тапшырган оешмаларның - IV куркыныч классындагы калдыкларны җыю, транспортлаштыру, эшкәртү, утильләштерү, йогышсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлек башкару турындагы лицензияләренең күчермәләре (Татарстан Республикасы буенча Росприроднадзор идарәсе)”;

“Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт” графасын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“№ 210-ФЗ Федераль законның 7 ст. 1 өл. 2 п.”;

2.13 пунктында:

“Стандарт таләбенең аталышы” графасын “, шул исәптән электрон рәвештә” сүзләре белән тулыландырырга;

“Стандарт таләбенең эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“Гариза кергән көнне”;

2.14 пунктында:

“Стандарт таләбенең аталышы” графасын “дәүләт хезмәте” сүзләреннән соң “, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән инвалидлар өчен күрсәтелгән объектларны Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә үтемлелек тәэмин итүгә, мондый хезмәтне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедия мәгълүматларын урнаштыруга һәм алар белән рәсмиләштерүгә карата” сүзләре белән тулыландырырга;

“Стандарт таләбенең эчтәлеге” графасында “инвалид коляскаларында каршылыксыз хәрәкәт итүне һәм әйләнүне тәэмин итә торган пандуслар, махсус киртәләр һәм тотынгычлар белән, каршылыксыз килүне һәм колясканы боруны исәпкә алып, керү ишегеннән булган якта инвалидлар өчен өстәлләр урнаштыру” сүзләрен өстәргә;

2.15 пунктында:

“Стандарт таләбенең аталышы” графасында “шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазифаи затлар белән хезмәттәшлек итү саны һәм аларның озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге” сүзләрен өстәргә;

“Стандарт таләбенең эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре:

кабул итү биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналарның тиешле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, “Интернет” челтәренең мәгълүмат ресурсларында, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан, гаризаны һәм документларны Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон документлар рәвешендә шәхси кабинеттан тапшырган очракта, (гаризаны һәм документларны Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон документлар рәвешендә тапшыру мөмкинлеге тормышка ашырылгач) дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәләрен электрон документлар рәвешендә Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетында алу мөмкинлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре:

документларны кабул итү һәм карау вакытларын саклау;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу вакытын саклау;

граждан хезмәткәрләре тарафыннан шушы Регламент бозылуга карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булу (Министрлыкның һәм Министрлыкның территориаль идарәләренең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазифаи затларының гомуми санына карата прецедентларның, шикаятьләр саны мөнәсәбәте);

мөрәҗәгать итүченең белгечләр белән хезмәттәшлек итү күләме:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда турында-туры – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны почта аша җибәргәндә, - юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон документлар рәвешендә шәхси кабинеттан тапшырганда:

1. әгәр гариза һәм документларның күчермәләре № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелә икән – турыдан-туры хезмәттәшлек итү таләп ителми;

2. әгәр гариза һәм документларның күчермәләре № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә җибәрелә икән – бердән артык түгел.

Мөрәҗәгать итүче белән бер тапкыр хезмәттәшлек итү озынлыгы – 15 минуттан артык түгел.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза тапшыруны алып, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтелми.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында, http://www.eco.tatarstan.ru сайтында алынырга мөмкин;

“Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт” графасын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“Тәртипнең 2.4 пунктында “п” пунктчасын”;

“Стандарт таләбенең эчтәлеге” графасындагы 2.16 пунктында “Министрлык бәяләмәсе” сүзләрен “Министрлыкның территориаль идарәсе бәяләмәсе” сүзләренә алмаштырырга;

3 кисәктә:

3 кисәк аталышын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакытлары, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында үтәү үзенчәлекләре”;

3.1.1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны рәсмиләштерү өлешендә”;

3.2 пунктын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультация алу өчен Министрлыкның әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормага салу бүлегенә (алга таба – Бүлек) һәм/яки Министрлыкның территориаль идарәсенә шәхсән, почта аша, телефон буенча, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша һәм (яки) электрон почта ярдәмендә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек һәм/яки Министрлыкның территориаль идарәсе белгече шәхсән, телефон аша, электрон почта буенча һәм (яки) хат белән, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның рәвеше һәм эчтәлеге буенча һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән аны рәсмиләштерү өлешендә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте алу өчен гаризаның рәвеше буенча һәм башка мәсьәләләрдә консультация, шулай ук күрсәтелгән ярдәм.”;

3.3.1 пунктында:

беренче абзацны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) шәхсән кәгазьдә, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә, Хисапны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлыкның территориаль органының бәяләмәсен алганда документларның төп нөсхәләрен алга таба тапшырып, яисә почта аша заказлы хат итеп, кулга тапшыру турында белдерүнамә белән, шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны (алга таба – документлар) теркәп, әлеге Регламентның 1 таблицасына туры китереп, Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә гариза бирә (җибәрә).”;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Күпфункцияле үзәк, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында дәүләт хезмәте күрсәтелми.”;

3.3.2 пунктында:

беренче абзацта “эш башкару бүлегенең” сүзләрен “Министрлыкның территориаль идарәсенең” сүзләренә алмаштырырга;

бишенче һәм җиденче абзацларда “Бүлекнең” сүзләрен “Министрлыкның территориаль идарәсенең” сүзләренә алмаштырырга;

3.3. 3 пунктын түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“3.3.3. Министрлыкның территориаль идарәсе башлыгы гаризаны һәм документларны карап тикшерү өчен җаваплы башкаручыны (алга таба – Министрлыкның территориаль идарәсе белгече) билгели һәм тапшырылган материалларны тиешле карар кабул итү өчен аңа тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрлыкның территориаль идарәсе белгеченә тапшырылган документлар”.;

3.3.4 пунктында:

беренче абзацны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“Министрлыкның территориаль идарәсе белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – ВЭХС) ярдәмендә Татарстан Республикасының Росприроднадзор идарәсенә хисап тапшыручы хуҗалык итүче субъектның I - IV куркыныч классындагы калдыкларны җыю, транспортлаштыру, эшкәртү, утильләштерү, йогышсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлек башкаруга карата (I - IV куркыныч классындагы калдыкларны җыю, транспортлаштыру, эшкәртү, утильләштерү, йогышсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлек башкаручы шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар өчен) лицензия һәм хисап тапшыручы хуҗалык итүче субъект хисап чорында I - IV куркыныч классындагы калдыкларны тапшырган оешмаларның I - IV куркыныч классындагы калдыкларны

җыю, транспортлаштыру, эшкәртү, утильләштерү, йогышсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлек башкару турындагы лицензияләр бирү турында электрон рәвештә гарызнамә җибәрә.”;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Сорала торган документлар (белешмәләр) җиткерүче тарафыннан законнарда билгеләнгән срокларда җибәрелгән гарызнамәләр нигезендә бирелә.”;

3.3.5 һәм 3.3.6 пунктларын түбәндәге редакцияләрендә бәян итәргә:

“3.3.5. Министрлыкның территориаль идарәсе белгече килгән белешмәләрнең шушы Регламентның 2.5 пункты нигезендә тапшырылган документлардагы күрсәтмәләргә туры килүен тикшерә.

Белешмәләр туры килгән очракта, шушы Регламентның 3.3.10 пунктында каралган процедуралар башкарыла.

Килгән мәгълүматлар аталган документлардагы күрсәтмәләргә туры килмәгән очракта, Министрлыкның территориаль идарәсе белгече:

ике нөсхәдә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли һәм аны документлар белән биргә имза салу өчен Министрлыкның территориаль идарәсе башлыгына җибәрә;

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, Хисапны кабул итүдән баш тарту турында хәбәр итә.

Шушы пунктчада билгеләнә торган процедуралар гарызнамәгә җавап килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ике нөсхәдә, Министрлыкның территориаль идарәсе башлыгына имза салу өчен җибәрелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

3.3.6. Министрлыкның территориаль идарәсе башлыгы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында ике нөсхәдәге хатка имза сала һәм Министрлыкның территориаль идарәсе белгеченә җибәрә.

Шушы пунктчада билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкның территориаль идарәсе белгеченә җибәрелгән, ике нөсхәдә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында имза салынган хат”.;

3.3.7 һәм 3.3.8 пунктларын көчен югалткан дип танырга;

3.3.9 һәм 3.3.10 пунктларын түбәндәге редакцияләрендә бәян итәргә:

“3.3.9. Министрлыкның территориаль идарәсе белгече:

хатны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының “Электрон Хөкүмәт” бердәм ведомствоара электрон системасында терки һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турындагы хатның беренче нөсхәсен мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып җибәрә,

хатның икенче нөсхәсен саклау өчен Министрлыкның территориаль идарәсе архивына җибәрә.

Шушы пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: беренче нөсхәсе мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән, икенче нөсхәсе Министрлыкның территориаль идарәсе архивына җибәрелгән, теркәлгән хат.

3.3.10. Министрлыкның территориаль идарәсе белгече:

тапшырылган документларның табигать саклау законнарындагы таләпләргә туры килүен тикшерә;

шушы Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә), гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, кисәтүләрне бетерү зарурлыгы турында хәбәр итә;

шушы Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаганда, Хисапны кабул итү турында ике нөсхәдә Министрлыкның территориаль идарәсе бәяләмәсе проектын әзерли;

шушы Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда ике нөсхәдә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли;

Министрлыкның территориаль идарәсенең Хисапны кабул итү турында бәяләмәсен яки баш тарту турында хат проектын килештерү өчен Министрлыкның территориаль идарәсе башлыгына җибәрә.

Шушы пунктчада билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.3.5 пунктчасында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 15 эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкның территориаль идарәсе башлыгына имза салу өчен җибәрелгән Министрлыкның территориаль идарәсенең Хисапны кабул итү турында бәяләмәсе проекты яки баш тарту турында хат проекты”.;

3.3.11 һәм 3.3.12 пунктларын көчен югалткан дип танырга;

3.3.13 - 3.3.16 пунктларын түбәндәге редакцияләрендә бәян итәргә:

“3.3.13. Министрлыкның территориаль идарәсе башлыгы ике нөсхәдә Министрлыкның территориаль идарәсенең Хисапны кабул итү турында бәяләмәсенә яки ике нөсхәдә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хатка (3 кушымта) имза сала һәм Министрлыкның территориаль идарәсе белгеченә җибәрә.

Шушы пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имза салынган Министрлыкның территориаль идарәсенең Хисапны кабул итү турында бәяләмәсе яки ике нөсхәдә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.3.14. Министрлыкның территориаль идарәсе белгече:

Хисапны кабул итү турында яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында мәгълүматны Министрлыкның Бердәм бүлеп бирелгән мәгълүмати-аналитик системасына (алга таба – ББМАС) кертә;

Министрлыкның территориаль идарәсенең Хисапны кабул итү турында бәяләмәсенең икенче нөсхәсен яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хатның икенче нөсхәсен саклау өчен архивка җибәрә.

Шушы пунктчада билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ББМАС кертелгән мәгълүмат, Министрлыкның территориаль идарәсе архивына җибәрелгән Министрлыкның территориаль идарәсенең Хисапны кабул итү турында бәяләмәсенең икенче нөсхәсе яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хатның икенче нөсхәсе.

3.3.15. Министрлыкның территориаль идарәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) Министрлыкның территориаль идарәсенең Хисапны кабул итү турында бәяләмәсенең беренче нөсхәсен тапшыра.

Шушы пунктчада билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән Министрлыкның территориаль идарәсенең Хисапны кабул итү турында бәяләмәсенең беренче нөсхәсе.

3.3.16. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда Министрлыкның территориаль идарәсе белгече баш тарту турындагы хатны электрон рәвештә бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында терки һәм мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура 3.3.14 пунктчада билгеләнгән процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән, мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән хат.”;

Түбәндәге эчтәлекле 3.4 пунктын өстәргә:

“3.4. Техник хаталарны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата) ачыкланганда, мөрәҗәгать итүче Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү гариза (5 кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документ;

техник хата (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата) булганлыгын таныклый торган, юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (аның вәкаләтле вәкиле) тарафыннан шәхсән тапшырыла, яки почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә) яисә бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелә.

3.4.2. Министрлыкның территориаль идарәсе белгече, теркәлгән документлары белән берлектә, техник хатаны (язу, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гаризаны кабул итеп ала һәм гаризаны электрон рәвештә бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында терки.

Шушы пунктчада билгеләнә торган процедура гариза кергән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен җибәрелгән кабул итеп алынган һәм теркәлгән гариза.

3.4.3. Министрлыкның территориаль идарәсе белгече документларны карап тикшерә һәм, дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында, төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкиленә) шәхсән яки имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкиленнән) техник хатасы (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документның төп нөсхәсен алып тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта аша (электрон почта ярдәмендә) Министрлыкның территориаль идарәсенә техник хатасы (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге булу турында хат җибәрә.

Шушы пунктчада билгеләнә торган процедура техник хата (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата) ачыклангannan соң яки теләсә нинди кызыксынган заттан җибәрелгән хата (язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата) турында гариза алынганнан соң өч көн дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ”.;

5 кисәкне түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

“5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазифаи затының, яисә дәүләт хезмәткәренең яки муниципаль хезмәткәрнең карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауларын) судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылу

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар Министрлыкның һәм/яки Министрлыкның территориаль идарәсенең, Министрлыкның һәм/яки Министрлыкның территориаль идарәсенең вазифаи затының, яки Министрлыкның һәм/яки Министрлыкның территориаль идарәсенең дәүләт гражданлык хезмәткәренең гамәлләрен (гамәл кылмауларын) судка кадәрге тәртиптә – Министрлыкка һәм/яки Министрлыкның территориаль идарәсенә шикаять кылырга хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтелү сәбәпле министрның карарларына гамәлләренә (гамәлләр кылмавына) карата шикаятьләр Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетына бирелә.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән, түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәсен теркәү вакыты бозылу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакыты бозылу;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту, әгәр дә мондый баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия

Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралмаган булса;

6) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәткәндә Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында каралмаган түләм таләп итү;

7) Министрлыкның һәм/яки Министрлыкның территориаль идарәсенең вазифаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда киткән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылганда.

5.2. Дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан шикаять почта аша, “Интернет” челтәре ярдәмендә, Интернет-кабул итү, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы, күпфукнцияле үзәк аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте алучыларның шикаятендә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять кылына торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазифаи затының, яисә дәүләт хезмәткәренең исеме;

мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр яисә мөрәҗәгать итүче – юридик затның аталышы, урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә җавап бирелергә мөмкин булган элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы;

дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять кылынучы карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүче шуларга нигезләнеп, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазифаи затының, яисә дәүләт хезмәткәренең каралары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән риза булмаган дәлилләр.

5.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга килгән шикаять шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазифаи зат тарафыннан аны теркәгән көннән алып 15 эш көне дәвамында, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазифаи заты мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуны яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылуны шикаять кылганда – аны теркәгән көннән соң биш эш көне дәвамында карап тикшерелерегә тиеш.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлүче документларның исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән яки вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча министр (ул булмаганда – ул вәкаләт биргән зат) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, Министрлык һәм/яки Министрлыкның территориаль идарәсенең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүе рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Шушы пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең ихтыяры белән электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки нәтиҗәсендә административ хокук бозу составы яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазифаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә”.;

1 кушымтаны яңа редакциясендә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый ресурслар
министрлыгының калдыклар
барлыкка килү, алардан файдалану,
аларны йогышсызландыру һәм
урнаштыру турында
хисап (статистика хисабыннан тыш)
тапшыру хакында бәяләмә бирү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
(Татарстан Республикасы Экология
һәм табигый ресурслар
министрлыгының 29.12.2015,
№ 1126-п боерыгы редакциясендә)
карата 1 кушымта

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының территориаль идарәсе бланкы**

Мөрәҗәгать итүченең исеме
Почта адресы

20__ ел өчен /Мөрәҗәгать итүченең исеме/ калдыклар барлыкка килү, алардан файдалану, аларны йогышсызландыру һәм урнаштыру турында Хисап материалларын (кер.№____, “___”_____________) карап тикшереп, Татарстан

Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының (алга таба – Министрлык) территориаль идарәсе түбәндәгеләр хакында хәбәр итә.

Тапшырылган материалларның составы Россия Федерациясе Табигый ресурслар һәм экология министрлыгының “Калдыклар барлыкка килү, алардан файдалану, аларны йогышсызландыру һәм урнаштыру турында хисапны (статистика хисабыннан тыш) тапшыру һәм контрольдә тоту тәртибен раслау хакында” 16.02.2010, № 30 боерык нигезләмәләренә туры килә”.

Тапшырылган материалларны карап тикшерү нәтиҗәсендә Министрлыкның территориаль идарәсе /Мөрәҗәгать итүченең исеме/ 20__ ел өчен калдыклар барлыкка килү, алардан файдалану, аларны йогышсызландыру һәм урнаштыру турында хисабын кабул итә.

Министрлыкның территориаль идарәсенә 20__ ел өчен Хисап тапшыру вакыты – 20__ елның 15 гыйнварына кадәр.

Калдыклар белән эш итү өлкәсендәге законнарның таләпләре үтәлешен тәэмин итү максатларында /Мөрәҗәгать итүченең исеме/ өчен түбәндәгеләр зарури:

Калдыклар барлыкка килүне, аларның хәрәкәтен һәм урнашуын даими рәвештә беренчел исәпкә алуны алып барырга;

барлыкка килә торган калдыкларны калдыкларны җыю, алардан файдалану, аларны йогышсызландыру һәм урнаштыру буенча эшчәнлеккә лицензиясе булган оешмаларга үз вакытында тапшырырга;

барлыкка килүче калдыкларның әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын киметүгә юнәлдерелгән чараларны башкарырга;

калдыкларны аралар җыю һәм эшчәнлек барышында барлыкка килүче калдыклардан икенчел ресурслар аерып чыгару бәрабәренә ККК полигонында урнаштырыла торган калдыкларның күләмен киметү буенча чаралар оештырылуны тәэмин итәргә;

әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен түләүләр кертергә.

Министрлыкның территориаль
идарәсе башлыгының яки аны
алмаштыручы затның имзасы ______________________ Фамилиясе, инициаллары

Җаваплы башкаручының фамилиясе,
телефон номеры”;

2 кушымтадагы “I-IV классындагы калдыкларны файдалану, йогышсызландыру, транспортлаштыру” сүзләрен “I-IV классындагы калдыкларны транспортлаштыру, эшкәртү, утильләштерү, куркынычсызландыру, урнаштыру” сүзләренә алмаштырырга;

3 кушымтада:

“ТР Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы бланкы” сүзләрен “ТР Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының территориаль идарәсе бланкы” сүзләренә алмаштырырга;


“Министр урынбасары имзасы” сүзләрен “Министрлыкның территориаль идарәсе башлыгы имзасы” сүзләренә алмаштырырга;

4 кушымтаны түбәндәге яңа редакциясендә бәян итәргә:


“Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый ресурслар
министрлыгының калдыклар
барлыкка килү, алардан файдалану,
аларны йогышсызландыру һәм
урнаштыру турында
хисап (статистика хисабыннан тыш)
тапшыру хакында бәяләмә бирү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
(Татарстан Республикасы Экология
һәм табигый ресурслар
министрлыгының 29.12.2015,
№ 1126-п боерыгы редакциясендә)
карата 4 кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема**

Мөрәҗәгать итүче




Министрлыкның территориаль идарәсе белгече



Министрлыкның территориаль идарә башлыгы

Җаваплы башкаручыны билгели, документларны карар кабул итү өчен җибәрә
1 эш көне

Белгечкә тапшырылган документлар

Министрлыкның территориаль идарәсе белгече

ВЭХС аша Татарстан Республикасы буенча Росприроднадзор идарәсенә электрон рәвештә гарызнамә җибәрә
1 эш көне

Белешмәләр бирү турында гарызнамә

Министрлыкның территориаль идарә белгече

Килгән мәгълүматларның документлардагы күрсәтмәләргә туры килүен тикшерә
1 эш көне

Белешмәләр документта күрсәтелгәннәргә туры киләме? 1 эш көне

әйе

юк

Шушы Регламентның 3.3.10 пп. күрсәтелгән процедураларны башкара
15 эш көне

Шушы Регламентның 3.3.5 пп.күрсәтелгән процедураларны башкара

Министрлыкның территориаль идарәсенең Хисапны кабул итү турында бәяләмәсе проектын әзерли

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты

Министрлыкның территориаль идарә башлыгы

Хисапны кабул итү турында бәяләмәгә имза сала
1 эш көне

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хатка имза сала
1 эш көне

Министрлыкның территориаль идарә белгече

Хисапны кабул итү турында мәгълүматны ББМАС кертә

1 эш көне

ББМАС кертелгән мәгълүмат

Министрлыкның территориаль идарә белгече

Мөрәҗәгать итүчегә Хисапны кабул итү турында бәяләмә яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат тапшыра

1 эш көне

Мөрәҗәгать итүчегә бирелгән Хисапны алу ту- турында бәяләмә яки теркәлгән һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән баш тарту турында хат

Түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

"Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый ресурслар
министрлыгының калдыклар
барлыкка килү, алардан файдалану,
аларны йогышсызландыру һәм
урнаштыру турында
хисап (статистика хисабыннан тыш)
тапшыру хакында бәяләмә бирү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
карата 5 кушымта

Татарстан Республикасы Экология һәм
табигый ресурслар министрлыгының
территориаль идарәсе башлыгына
_______________________________________
кемнән: _____________________________________

**Техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза**

________________________________________________________________дәүләт хезмәтен
(хезмәтнең исеме)

күрсәткәндә җибәрелгән хата (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата) турында хәбәр итәм

Язылган: ____________________________________________________________
______________________________________________________________________

Дөрес белешмәләр: ___________________________________________________
______________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтүне һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

электрон документ рәвешендә шушы E-mail адресына:
________________________;

түбәндәге адрес буенча, кәгазьдә, таныкланган күчермә рәвешендә:
_________________________________________________________________.

Шәхси белешмәләрне, шул исәптән автоматлаштырылган режимда, алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан карарлар кабул ителүне исәпкә алып, эшкәртү өчен (җыю, системага салу, туплау, саклау, тәгаенләү (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрен бетерү, ябу, шәхси белешмәләрне юкка чыгару, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә) үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан вәкаләт бирелгән затның ризалыгын раслыйм

Хәзергесе белән түбәндәгеләрне раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм минем тарафтан вәкаләт бирелгән затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны бирү вакытына әлеге документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларга ия.

Түбәндәге телефон аша миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашу буенча үз ризалыгымны бирәм: ____________________.

_______________ ___________________ ( __________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А.)”

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (В.А.Тронин) әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту өчен министрның беренче урынбасары Р.И.Камаловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Ф.С. Габделганиев